| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА<br>МАЛОБУИНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР БУАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

---

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| «15» ноябрь 2021 ел | № 5 |

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Татар Буасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 3-20 нгомерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» карары нигезендә, Татар Буасы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү юлы белән «Татар Буасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләре турындагы проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында


КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Татар Буасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрүне Татарстан Республикасы, Буа районы, Татар Буасы авылы, Яшьләр ур., 33А йорт адресы буенча Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 10 декабренә 11.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Гавами (ачык) тыңлауларда фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2021 елның 09 декабренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татар Буасы авылы, Яшьләр ур., 33А йорт, Татар Буасы авыл җирлеге Башкарма комитеты, телефон +7(84374) 3-36-45.
3. Әлеге карар Татар Буасы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш:
- ТР, Буа районы, Татар Буасы авылы, Яшьләр урамы, 2А йорт;
- ТР, Буа районы, Татар Буасы авылы, Яшьләр урамы, 33А йорт.
4. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татар Буасы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземә йөклим.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Татар Буасы авыл
җирлеге башлыгы Р.Ф. Йосыпов

Приложение к постановлению главы
Малобуинковского сельского
поселения
Буинского муниципального района РТ
от «15» ноября 2021 г. № 5

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләр исәпкә алынган карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- Буа муниципаль районы чиге
- Муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Түбән Наратбаш авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- В-Г - Ырынгы авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Г-Д - Татар Буасы авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Җирлекләрнең административ үзәкләре
- Торак пунктлар

- Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Ырынгы авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе